ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.06.2024 г. № 651

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым административ регламентларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә үз көчләрен югалтуын тану турында**

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең түбәндәге административ регламентларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 27 июлендәге 682 номерлы карары белән расланган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

«Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 27 июлендәге 682 номерлы карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

«Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 27 июлендәге 682 номерлы карары белән расланган объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

«Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елнын 27 июлендәге 682 номерлы карары белән расланган җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 елның 1 октябрендәге 842 номерлы карары белән расланган рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.С. Игтисамовка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы
Җитәкче урынбасары Р.С. Игтисамов